БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

| Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №31 (7048) | 15 март, 1990 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен. |
|---|---|---|---|

## СССР халык депутатлары Съездында



МӘСКӘҮ (ТАСС). 13 мартта СССР халык депутатларының чираттан тыш III съездында алдагы көндә СССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм СССРда Президент посты булдыру турындагы мәсьәләне тикшерү дәвам итте.

Фикер алышуларда катнашучылар хәзер власть чын-чынлап функциясен башкармый торган ситуация уңаеннан борчу белдерделәр. Аның ролен йомшартуы җәмгыятьтәге күпсанлы социаль-экономик проблемаларны тирәнәйтә, билгеләнгән реформаны тоткарлауга китерә, милләтара нигездә конфликтны кискенләштерә, тәртипсезлек, җинаятьләрнең үсешен тудыра. Ораторлар Совет дәүләте белән җитәкчелекне оештыруга яңача килүне, хәрәкәтчән идарә механизмы төзүне таләп итәләр.

Шул уңайдан күпләр идарә итүнең президент формасын кертү турындагы мәсьәләне кичектергесез хәл итү кирәклеген әйттеләр. СССРда Президент постын раслау илдә бүген анархия, законсызлык һәм барына да ирек кую тарафдарлары тотырган үзенчәлекле власть вакуумына каршы гарантия буларак характерланды.

Үзләре әйтүе буенча, президентлык кертүгә ашыгуга каршы депутатлар —кайбер регионара депутат группалары һәм союздаш республикалар вәкилләре президентлык власте институты булдыруның мәгълүм шартларын белдерделәр. Болар —яңа суверен дәүләткә союз договоры, президент эшчәнлегенә коллегиаль контроль буенча эффектлы механизм төзү, аны турыдан-туры һәм гомуми тавыш бирү юлы белән сайлау, күп партияле сайлаулар үткәрү.

Тикшерелә торган закон проектына бик күп замечаниеләр, төзәтмәләр, өстәмәләр кертелде. Аларны съезд тарафыннан төзелгән редакция комиссиясе караган.

МӘСКӘҮ (ТАСС). Советлар Союзында Президент посты булдырылды. 13 мартта Съездның кичке утырышында СССР Президент посты булдыру турындагы Закон проектының беренче өлешен кабул итеп һәм СССР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, 1817 халык депутаты бу фикерне яклап тавыш бирде (133 каршы, 61 се тоткарланды).

Бу пост, диелә документта, илдә бара торган тирән политик һәм экономик үзгәрешләрне тагы да үстерүне, Конституция строен, гражданнарның хокукларын, ирек һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында булдырыла.

14 мартта Съездның иртәнге утырышында Конституция положениесенә берничә үзгәреш кертү мәсьәләсен закон нигезендә хәл кылырга тәкъдим ителде.

СССР Конституциясенә политик система мәсьәләләре буенча (СССР Конституциясенең 6—7 статьялары) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелде. Бу статьяларның яңа редакциясе демократияне тагы да үстерү, җәмгыятьтә политик плюрализмны ныгыту белән турыдан-туры бәйле.

СССР Конституциясенең экономик системаның төп элементларын билгеләүче статьяларына да кардиналь үзгәрешләр кертелде. Бу яңа положениеләрнең нигезе булып күптән түгел кабул ителгән СССРда милек турында Закон һәм җир турында Закон нигезләре торды.

Илнең Төп Законында Президент сайлау тәртипләре, аның вәкаләте һәм җаваплылыгы, башка дәүләт органнары белән мөнәсәбәте билгеләнгән махсус бүлек кертү каралган.

СССР халык депутатлары Съезды эшен дәвам итә.

## Ышаныч уятты

226 нчы Завод сайлау округы буенча ТАССР халык депутатлыгына кандидат Л. Н. Газизуллина «Россия» һәм Кузнецов исемендәге колхоз вәкилләре белән очрашуда булды. Кандидатның сайлау алды платформасын, аның ышанычлысы Л. Дильмөхәмматова чыгышын тыңлаганнан соң, сайлаучылар күпсанлы сорауларга җаваплар алдылар. Очрашу сайлаучыларда депутатлыкка кандидатка карата зур ышаныч һәм хөрмәт уятты.

Шундый ук әчкерсез очрашу Богдашкино авылы сайлаучылары белән дә үтте. Сайлаучыларның күбесе халык депутатларын сайлаулар буенча кабат сайлаулар вакытында Л. Н. Газизуллина исемен яклап тавыш бирергә вәгъдә итте.

Л. РУССКАЯ.

## 1990 елның 4 мартында халык депутатларының XXI чакырылыш Норлат шәһәр һәм авыл Советларына халык депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре турында БЕЛДЕРҮ

Халык депутатларының Октябрь район Советы башкарма комитетына халык депутатларының Норлат шәһәр һәм авыл Советлары башкарма комитетларыннан Октябрь районы буенча шәһәр һәм авыл Советларына халык депутатларын сайлау турында нәтиҗәләр керде.

Сайлаулар халык депутатларының бер шәһәр һәм 25 авыл Советларында үткәрелде. Халык депутатларын сайлау буенча районның шәһәр һәм авыл Советлары сайлаучылар исемлегенә 38 мең 537 сайлаучы кертелгән иде. Халык депутатларын сайлауларда шәһәр Советында 13090, авыл Советларында 20849 кеше катнашты.

Татарстан АССРга халык депутатларын сайлау турында Татарстан АССР Законының 48 статьясы нигезендә халык депутатларының шәһәр Советына сайлауларда 93, авыл Советларында 544 бюллетень яраксыз дип табылды.

Татарстан АССР халык депутатлары җирле Советларына халык депутатларын сайлаулар турында Татарстан АССР Законының 51 статьясы нигезендә барлыгы депутатлар сайланды: шәһәр Советына 34, авыл Советларына 420. Шәһәр Советы халык депутатлары арасында 13 эшче, 15 хатын-кыз, 30 га кадәрге яшьләр 7 әү, 18 партия члены, 16 партиясез. 5 ВЛКСМ члены. 23 халык депутаты беренче тапкыр сайлана.

Авыл Советлары депутатлары арасында: 46 эшче, 214 колхозчы, 72 кеше 30 гача яшьләр, 233 депутат беренче тапкыр сайланды.

Татарстан АССР халык депутатлары җирле Советларына халык депутатларын сайлаулар турында Татарстан АССР Законының 53 статьясы нигезендә шәһәр Советының бер, авыл Советларының 10 сайлау участогында халык депутатларын сайлау буенча кабат сайлаулар үткәрелә.

**Халык депутатларының Октябрь район Советы башкарма комитеты.**

**Таныш булыгыз: фабрика тегүчеләре**



**Яңа фабриканыкы, дип тә әстисе килә. Чөнки Чистай тегү фабрикасы филиалы бездә икенче елын гына эшли әле. Әмма коллектив беренче уңганнарны билгели инде. Аларның берсе— Галина Николаевна Малыгина. Элегрәк, тегү училищесында алган белеме бик ярап куйды Галина Николаевнага Норлатка килгәч. Башта фабрикага тегүче-моторист булып урнашты, аннан аны ясле яшендәге ир балалар өчен күлмәкләр тегү цехына смена мастеры итеп куйдылар. Түземле һәм ягымлы Галина Николаевна кул астындагы кызлар белән уртак телне тиз тапты. Тегүче һөнәре осталыкларын иренмичә, тәләп аңлата ул. Рәсемдә сез аны яшь өйрәнчек Роза Моратова белән күрәсез. Кызның белергә, өйрәнергә теләге зур, ә мастерга шул гына кирәк тә: күрсәтә, аңлата, бер сүз белән әйткәндә—һөнәргә юл ача ул.**

## Якташларга әйтер сүзем

**17 мартта, билгеле булганча, РСФСР халык депутатларына кандидатларга кабат тавыш бирү үткәреләчәк. 868 нче территориаль сайлау округы буенча депутатлыкка кандидатлар арасында якташыбыз Миндамир Мәхмүтович Мусин да бар.**

**Шушы уңайдан минем районда яшәүче барлык сайлаучыларга әйтер сүзем бар. Кабат тавыш бирү көнендә тавышларыбызны Миндамир Мәхмүт улы Мусинга бирик. Моны шуның өчен дә әйтүем. СССР халык депутатлары арасында безнең районнан вәкил юк. РСФСРда безнең үз кешебез булу районыбыз проблемаларын хәл итүдә булышлык итәр иде. Миндамир Мәхмүтович моңа сәләтле. Районыбыз сайлаучылары шуны да исәпкә алсыннар иде.**

**127 нче Чирмешән милли-территориаль сайлау округы буенча ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Ринат Сафиевич Мөхәммәдиевны якларга чакырам. Аның республикада демократияне киң җәелдерү, әдәбият һәм мәдәниятны үстерүдә куйган хезмәтләре зур. Ул— Татарстанга союздаш республика статусы бирү өчен актив көрәшүчеләрнең берсе. Шуңа аны РСФСР дәүләт властеның югары органына сайласак ялгышмабыз.**

**И. ПЕТРОВ,**

тимер юлчы, сугыш һәм хезмәт ветераннарының район Советы председателе.

## Белдерү

РСФСР халык депутатларын сайлаулар буенча территориаль һәм милли территориаль сайлау округларында кабат тавыш бирү 1990 елның 17 мартында, шимбә көнне, элекке сайлау участокларында 7 сәгатьтән 20 сәгатькә кадәр үткәрелә.

Шул ук тәртиптә 226 Завод һәм 227 Октябрь сайлау участокларында ТАССРга халык депутатларын сайлау да үткәреләчәк.

**РАЙОН СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ.**

